

БЕЗГӘ
30
ЯШЬ
Салават күпере
МАРТ
2020
МАХСУС САН
ТАССР 1920-2020

ӘТИ-ӘНИЕҢНӘН СОРА ӘЛЕ...

Әти-әниеңнән сора әле. Алар «Салават күпере»н укып үсте микән? Күктәге салават күпере кебек бу бик матур журнал 30 ел буена чыга инде. Сорап кара әле... Балачакта укыдылармы икән?

Мәгәр укып үскән булсалар, сиңа ул турыда тәмләп сөйләсеннәр. Күрмәгән булсалар – бергәләп укыгыз. Һәм шул хакта безгә хат язып җибәрегез. Бүген «Салават күпере»нең бәйрәме бит. Бәйрәм булгач, сезгә бүләкләр дә булыр – шигырьләр тупланган китапчык! Һәм, әлбәттә, утыз ел буе басылган энҗеләр. Алар арасында шаккатмалы әкиятләр, матур шигырь-хикәятләр, кызыклы уеннар һәм мәзәкләр бар.

Күктәге салават күперен күргәнегез бар ич инде? Нинди матур бит ул! Синең кулыңда да нәкъ шундый ук матур журнал! Алар икесе дә синең нәни йөрәгеңә гүзәллек бирер. Җаның җылынып китәр. Рәхәт, бик рәхәт булыр сиңа...

Менә тиздән дәү үсеп җитәрсең. Күңелең салават күпере кебек матур булыр. Күңеле матур кеше рухи яктан да бай була. Бай буласың киләдер бит?..

Бай һәм бәхетле бул, нәни укучым!


Зиннур Хөснияр,
журналга нигез салган
беренче баш мөхәррир.


ДУСТЫМ! «САЛАВАТ КҮПЕРЕ»НДӘ ЭШЛӘҮЧЕ АБЫЙ-АПАЛАР ДА КАЙЧАНДЫР СИНЕҢ КЕБЕК КЕЧКЕНӘ БУЛГАН. АЛАРНЫҢ БАЛАЧАКТАГЫ ФОТОРӘСЕМНӘРЕН ХӘЗЕРГЕЛӘРЕ БЕЛӘН ТОТАШТЫР.



Григорий Әйдинов рәсеме






















Фәридә Харрасова рәсеме

№7, 1995 ел





Фәрит Муллахмәт рәсеме

Борын-борын заманда бер әтәч яшәгән. Беркөнне ул, түшен кабартып, як-ягына карангалап, эре генә атлап йөргән-йөргән дә бер биек койма башына менеп баскан ди. Менеп баскан да:

– Ки-ке-ри-күк! Мин – ханәтәч, мин – патша-әтәч! – дип кычкыра башлаган ди. – Сөекле карабикәләрем, акбикәләрем, чуарбикәләрем! Әйтегезче, дөньяда матурлардан да матур кем матур, батырлардан да батыр кем батыр?

Шул тирәдә йөргән тавыклар йөгерә-йөгерә моның янына җыелганнар да:

– Кая инде ул безнең шаһыбыз, сөекле падишаһыбыз белән тиңләшерлек әтәч? Юк ул, юк? Синнән дә матур, синнән дә батыр әтәч юк инде бу дөньяда! – дип мактарга тотынганнар ди...

Әтәч масаюыннан шартлый язган ди. Шуннан соң кикриген тагын да югарырак чөеп җибәргән һәм:

– Ки-ке-ри-күк! Карагыз әле, дөньяда кемнең тәхете биегрәк тә, кемнең башындагы таҗы затлырак? – дип сораган.

Тавыклар, кукраеп утырган әтәчкә башларын иеп:

– Тәхетләрдән биек – синең тәхет биек, таҗлардан затлы – синең таҗың затлы! Син – безнең бердәнбер шаһыбыз, син – безнең бердәнбер падишаһыбыз! – дип әйткәннәр ди.

Шул арада өйдән хуҗа чыккан да, аяк очларына гына басып, койма янына килгән һәм ачы итеп сызгырып җибәргән. Тавыклар алдында масаеп торган патша-әтәч койма башыннан җиргә егылып төшкән дә, куркуыннан нишләргә белмичә, абзар янына элдергән...

Хәзер инде кем патша?



НӘРСӘ УЛ САЛАВАТ КҮПЕРЕ?

– Минем яраткан журналым! – дип ашыга-ашыга җавап бирерсең син һәм ялгышмассың.

– Яңгырдан соң күренә торган бик матур дуга, – диярләр башкалар. Алар да хаклы булыр.

«Салават күпере» журналы хәзер синең кулыңда. Ертмасаң, бөгәрләмәсәң, кат-кат алып укырсың әле аны. Ә күктәге салават күперенең гомере бик кыска. Ник микән? Гомумән, нәрсә ул – салават күпере? Нәрсәдән ясалган ул?

Яңгыр явып та карады соң! Чиләкләп койды. Һавалар сафланды, сулыш алулары рәхәт булып китте. Бушап, җиңеләеп калган болытларны аралап, кояш та балкып килеп чыкты. Шунда ук күк йөзен иңләп-буйлап салават күпере сузылды!

Салават күпере бары яңгырдан соң гына чыга. Яңгыр узса да, һавада әле бик-бик күп вак су тамчылары кала. Кояш нурлары шул тамчыларга бәрелеп сыналар, яктылык җиде төскә таркала: кызыл, кызгылт-сары, сары, яшел, зәңгәрсу, куе зәңгәр, шәмәхә... Менә шул төсле дуга салават күпере була инде.



Фәрит Муллахмәт рәсеме

№5, 1991 ел



Илгизәр СОЛТАН

СЫЕРЧЫК

Әллә кояш көлгәнгәме,
Әллә мине күргәнгәме,
Әллә инде бу ояны
Мин элгәнне белгәнгәме? –
Сайрый шатланып сыерчык,
Әйләнеп килә очып.
...Сурәткә төшәсем килә,
Шул сыерчыкны кочып.

Мөхәррәм КАЮМ

ЯҢГЫР

Күксел эшләпәсен киеп,
Көмеш сакаллы чал карт
Сиздермичә генә килде
Зур таулар аша атлап.

Җир колагына пышылдап,
Ниндидер серен ачты.
Шуны ишетик дигәндәй,
Үләннәр үрә басты.

Айдар Үтәгән рәсеме

№10, 1991 ел

Ләбиб Леерон

Хыялый Акбай

Яшәгән ди Акбай дигән бер эт. Ул күк йөзенә текәлеп хыялланырга яраткан.

– Их, самолёт кебек очсан иде!





– Юк, самолёт булмыйм. Йә егылып төшәрмен...

– Әгәр матай булсам?!



Юрий Денисов рәсеме



– Юк, йә ялгыш коймага-мазар бәрелермен...


– Иң яхшысы – моторлы көймә булу!






– Суга батсам нишләрмен?

– Трамвай булсаң иде ул! Рельс буйлап келтер-келтер чабасың...



– Чатыр чаба торгач, рельстан чыгып китсәм...



– Әгәр... Әгәр эт булсам! Һай! Үзем эт ләбаса! Үзең булуга, эт булуга ни җитә?



Хуҗаңа булышасың: йорт саклыйсың... Анда-монда чабасың... Рәхәт!

№9, 1992 е


Фәрит ЯКУПОВ рәсеме
Рәссам абыегыз бу рәсемдә
нинди ялгышлар җибәргән?
Шуларны табыгыз әле.

№3, 1992 ел

Рөстәм Мингалим



Яшел күзле әнием



Мин хәзер зур. Кайчандыр кечкенә чагым да булган.

Көчкә-көчкә генә басып, бер урында гына басып тора белгән курчак шикелле булганмын.

Кайвакыт шундый итеп егылганмын... Кат-кат исememне әйтеп тә, уенчыклар күрсәтеп тә, кулында тирбәтеп тә, әнкәй мине юата алмаган. Авызымны йомарга онытып, тавышым белән бөтен өйне тутырып елаганмын... Ул чагында минем тавышым да, авызым да үземнән зур булган.

Үзем тиз үскәнмен. Аның саен тизрәк үсәргә, тизрәк йөреп китәргә тырышканмын. Тырыша торгач, бишектән дә егылып төшкәнмен.

Монысын хәтерләмим.


Хәтерлим шуны: җәй, җылы, кояшлы көн иде. Су буенда төркем-төркем ак казлар йөри. Таллар яшел. Таулар яшел. Ярлар яшел. Безнең бакча башындагы елганың сай, төбе ташлы җирендә су тырпылдап ага. Әнкәй белән җитәкләшеп, елганың аръягына – әрәмәгә чыгабыз. Су уртасына җиткәч, ни өчендер әнкәй миңа иелеп карады. Шулвакыт мин аның зур күзләрен күрдем...

Күзләре яшел икән, яшел талларга, ярларга, тауларга охшаган. Аның күзләре – яшел җәйнең яшел күзләре шикелле.

Безнең авылдагы әниләрнең иң матуры – минем әнкәй. Бу уемны дусларым Нәҗип белән Наилгә дә әйттем. «Минем әни матуррак!» – диде Наил. Нәҗип тә бәхәсләшә. «Минем әни матуррак!» – ди.

Бәхәсләшә торгач, ул көнне без сугыша яздык. Ярый шунда безне эзләп су буена әниләребез килде. Барыбер, аларның иң матуры минем әнкәй иде. Минем әнкәй, яшел күзле әнкәем... Ул чакта мин шуны да күрдем: Нәҗипнең әнисе зәңгәр күзле, Наилнең әнисе кара күзле икән...

Мин хәзер зур. Сабый чагымны сагынып, авылыма кайтам. Хәзер әнкәем дә юк. Ә җәйләр миңа һаман әнкәемнең яшел күзләре белән карыйлар...


Фәрит Муллахмәт рәсеме



Чарасын тапкан

МӘЗӘК

Бер нәни кыз әнисенә әйтә икән:
– Әни! Сөт чиләгенә тычкан төшкән!
– Төшсә ни хәл итәсең инде, кызым? Алып ташлагансыңдыр бит? – дигән әнисе.
– Юк, тотарга курыктым. Тычканны тотарга дип, песине дә чиләккә ташладым! – дигән нәни кыз.




Фәрит Якупов рәсеме

Читәнме, бүзме?

ШАЯРУ

Бер бала, арттан килеп,
икенчесенең күзен каплый.
– Читәнме, бүзме?
– Бүз.
– Бер чеметкәнгә түз.
– Алайса, читән.
– Бер чеметәм дә китәм!





Әкият башы

Мич астыннан ни аулап
Чыкты мәче мияулап?..
Бу тик әкиятнең баласы,
Мич башында ята бабасы,
Коймак изә әбисе,
Таба майлый анасы.
Табагачтыр, коймактыр,
Сөйләгәнне тыңлап тор.
Иләктер дә чиләктер,
Колагыннан эләктер.



Эт кычкыра, мин өрәм

ЧУАЛТМЫШ

Ыргадан, мыргадан,
Төшеп калдым арбадан,
Эт кычкыра, мин өрәм,
Ат йөгерә, мин чабам,
Тәртә өзелде, бау сынды,
Аптырадым бит тәмам.




Рәссам Айдар ҮТӘГӘН





Ике рәсемнән ун аерма тап.





Рәссам остаракмы, синме? Рәсемне буяп, үзеңне сынап кара.

№8, 1992 ел

КИРЛЕМӘН КИҢӘШЛӘРЕ

Әгәр әниең: «Эшкә соңга калам инде!» – дия-дия, ашыга-ашыга, сине киендерергә азаплана икән, киенмәскә тырыш. «Бу оекбашны кимим! Күлмәкнең бусы ошамый!» – диген. Тыпырчына-тыпырчына еларга тырыш. Берәр җиреңә «чәп» иттереп тә алсалар, отыры кычкырыбрак еласаң да ярый. Шәрран ярып акырганыңны ишеткән күрше-күләннәр сиңа бик сокланырлар: «Карале, безнең күршедә генә нинди елак бала үсә икән! Бигрәк матур итеп елый инде!» – диярләр.

Елыйсың килми башласа, көчәнмә. Көчеңне сакла. Әле синең киреләнә-киреләнә елыйсыларың көне буена шактый булачак.



Рәссам Елена ХИТРОВА

№2, 1991 ел

№3(360) – 2020

«Салават күпере» журналы

1990 елның март аеннан бирле чыга.

0+ **Мәктәпкәчә яшьтәге балаларга (өлкәннәр тарафыннан балаларга уку өчен) һәм кече яшьтәге мәктәп балаларына тәкъдим ителә.**

Филиал җитәкчесе
Зиннур Хөснияр (Зиннур Зыятдин улы ХӨСНЕТДИНОВ)

Баш мөхәррир
Зилә Зиннур кызы ХӨСНЕТДИНОВА

Баш мөхәррир урынбасары
Гөлназ ЯРМИЕВА

Баш рәссам һәм компьютер дизайны
Әлфия ЙОСЫПОВА

Мөхәррирләр
Олеся ДМИТРИЕВА
Гөлнара ХӘЙДӘРОВА
Эльвира САБИРОВА

Исәп-хисапчылар
Светлана СИДНЕВА
Резедә ШАГАПОВА



Гамәлгә куючы: «ТАТМЕДИА» АҖ. Адресы: 420097, Казан шәһ., Академия ур., 2 йорт.

«Татмедиа» Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы ярдәмендә чыгарыла.

Нәшер итүче: «ТАТМЕДИА» АҖ. Адресы: 420097, Казан шәһ., Академия ур., 2 йорт.

Журнал элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр даирәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәт (Роскомнадзор) тарафыннан 2019 елның 1 октябрендә теркәлде. Теркәлү таныклыгы **ПИ № ФС77-76908**.

Журнал айга бер тапкыр нәшер ителә.
Чыгу көне: 11.03.20
Кәгазь форматы: 60x90 1/8.
Гарнитура: PT Sans.
Заказ: А–429. Тираж: 7150 данә.
Бәясе ирекле. Язылу индексы:
Татарстанда – **П2339**,
Россиядә – **73953**.

Тышлыкта – Фәрит Муллахмәт рәсеме.


Редакция адресы: 420066, Казан ш., Декабристлар ур., 2 й., 7 кат.
Телефон: (843) 222-05-46 (1646)

E-mail: salavatkupere@mail.ru
Сайт: salavatkupere.com
Социаль челтәрләр:
vk.com/salavatkupere
facebook.com/salavatkuperejournal
twitter.com/salavatkupere
instagram.com/salavatkupere

«ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды. Адресы: 420066, Казан шәһ., Декабристлар ур., 2 йорт.

Материалларны тулысынча яки өлешчә куллану бары тик редакциядән язмача рөхсәт булганда гына мөмкин.

«САЛАВАТ КҮПЕРЕ» ЖУРНАЛЫ



Рамил Курамшин көе, Ринат Мәннан сүзләре

Күңелле итеп.












Кушымта.













«Салават күпере» килә,
Уен-көлкегә баеп.
Хат ташучы илтә аны
Һәрбер өйгә, елмаеп.

Кушымта:
Укыйм, ятлыйм шигырьләрен,
Әкиятен – барысын!..
Әйдә, син дә укып кара –
Бик канәгать калырсың.

«Салават күпере» кирәк
Һәр кызга, һәр малайга...
Әбием белән укыйбыз,
Бик ярата бабай да!

Кушымта.

«Салават күпере» белән
Дөньяларны мин гизәм, –
Иң яраткан журналым ул,
Өемә килә тиздән.

Кушымта.